# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“15” ноябрь 2023 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 13 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2023 елның 15 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән “Сез 2024 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Чишмәле Сап авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау;

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 216 (ике йөз уналты) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан граҗданнар саны 126 (бер йөз егерме алты) кеше, бу 58 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 126 (бер йөз егерме алты) кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2024 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Чишмәле Сап авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау;

мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.